СОВЕТ ШЕЛАНГОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ШИЛАНГЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ                                        КАРАР

__29.12.2016 №        с. Шеланга        ______________

«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге Советы карары проекты турында

Югары Ослан муниципаль районының Шеланга авыл җирлеге Уставын «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 44 статьясына һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына, Югары Ослан муниципаль районының Шеланга авыл җирлегенең 19, 97-99 статьяларына, Югары Ослан муниципаль районының Шеланга авыл җирлеге Советының 2007 елның 25 июнендәге 98-98 номерлы карары белән расланган Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлегенең Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проектына гавами тыңлаулар уздыру тәртибенә таянып, гамәлдәге кануннарга туры китерү максатыннан

Югары Ослан муниципаль районы
Шеланга авыл җирлеге Советы
карар итте

1. Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге Советы карары проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм, тәкъдимнәрне, төзәтмәләрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, аның өстендә эшләүне дәвам итәргә (1 нче кушымта).

2. Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге Уставында үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү буенча тәкъдимнәр кабул итү, исәпкә алу һәм карау буенча түбәндәге составта эш төркеме төзергә:

- эш төркеме рәисе, Югары Ослан муниципаль районының Шеланга авыл җирлеге башлыгы В.В.Майоров;

- эш төркеме секретаре, Югары Ослан муниципаль районының Шеланга авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе Антонова Н.В.;

Эшче төркем әгъзалары:

- Сандомирова Любовь Александровна - мәдәният йорты мөдире
- Синичкина Любовь Сергеевна - Шеланга авыл китапханәсе мөдире
- Беляев Анатолий Павлович - пенсионер

3. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге Советы Карары проектына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен расларга (2 нче кушымта).

4. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Шеланга авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гражданнарның катнашу тәртибен расларга (3 нче кушымта).

5. Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү буенча ачык тыңлауларны 2017 елның 14 гыйнварында 10.00 сәгатьтә Югары Ослан муниципаль районы Шеланга мәдәният йортында, Шеланга авылы, Октябрь урамы, 53 йорт адресы буенча үткәрергә.

6. Югары Ослан муниципаль районының Шеланга авыл җирлегендә яшәүчеләрнең кергән тәкъдимнәрен гомумиләштерергә һәм аларны Югары Ослан муниципаль районының Шеланга авыл җирлеге Советы каравына кертергә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Шеланга авыл җирлеге башлыгы В.В.Майоров

Югары Ослан муниципаль
районы Шеланга авыл
җирлеге Советының 2016
елның 29 декабрендәге 16-69
номерлы карарына

1 нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

Югары Ослан муниципаль районының Шеланга авыл җирлеге Уставына түбәндәге эчтәлекле үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1. Уставның 7.1 статьясындагы 1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 13 пунктча өстәргә:

«13) «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыру»;

2. Уставның 48 статьясындагы 7 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында” 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыра”;

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Шеланга авыл җирлеге башлыгы В. В. Майоров

Югары Ослан муниципаль районы
Шеланга авыл җирлеге Советының
2016 елның 29 декабрендәге 16-69
номерлы карарына

2нче кушымта

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШЕЛАНГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ УСТАВЫНА ҮЗГӘРЕШЛӘР ҺӘМ ӨСТӘМӘЛӘР КЕРТҮ ТУРЫНДА»ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШЕЛАНГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ КАРАРЫ ПРОЕКТЫНА ГРАЖДАННАРНЫҢ ТӘКЪДИМНӘРЕН ИСӘПКӘ АЛУ ТӘРТИБЕ.

1. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Шеланга авыл җирлеге советы проектына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге карары проектына тәкъдимнәр, Ф.И.О. күрсәтелгән язма рәвештә, авторның яшәү урыны турында белешмәләр дә 2017 елның 14 гыйнварына кадәр кертелә. Тәкъдимнәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 422577, Шеланга авылы, Октябрь ур., 53 нче йорт Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге Советына эш төркеме секретаре Антонова Н.В.торак пунктның мәгълүмат стендларында һәр көнне якшәмбедән тыш 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр, шимбә көнне 8.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр. Белешмәләр өчен телефон: 20-4-75

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Шеланга авыл җирлеге башлыгы В.В.Майоров

Югары Ослан муниципаль районы
Шеланга авыл җирлеге Советының
2016 елның 29 декабрендәге 16-69
номерлы карарына

3нче кушымта

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШЕЛАНГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ УСТАВЫНА ҮЗГӘРЕШЛӘР ҺӘМ ӨСТӘМӘЛӘР КЕРТҮ ТУРЫНДА»ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШЕЛАНГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ КАРАРЫ ПРОЕКТЫ БУЕНЧА ФИКЕР АЛЫШУДА ГРАЖДАННАР КАТНАШУ ТӘРТИБЕ

1. Чыгыш хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен заявкалар түбәндәге адрес буенча бирелә: 422577, Татарстан Республикасы, Югары Ослан муниципаль районы, Шеланга авылы, Октябрь урамы, 53 йорт Югары Ослан муниципаль районының Шеланга авыл җирлеге башкарма комитетында В.В.Майоровка шәхсән яисә почта аша (конвертта «Устав турында фикер алышу» тамгасы белән).

2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Шеланга авыл җирлеге советына язмача гариза биргән җирлек халкы үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен гавами тыңлауларда катнашучылар булып тора.

3. Гавами тыңлауларда гавами тыңлауларда катнашу хокукыннан башка Җирлекнең барлык кызыксынучы кешеләр дә катнашырга мөмкин.

4. Катнашучыларны теркәү гавами тыңлаулар башланганчы 30 минут кала башлана.

5. Чыгыш хокукы белән гавами тыңлауларда катнашучылар гариза бирү вакытына бәйле рәвештә чиратлылык тәртибендә үз тәкъдимнәрен аргументацияләү өчен чакырыла.

6. Гавами тыңлауларда катнашучыларның чыгышлары 5 минуттан артык дәвам итәргә тиеш түгел.

7. Гавами тыңлауларда катнашучылар утырыш тәмамланганнан соң чыгыш ясаучыларга председатель рөхсәте белән сораулар бирергә хокуклы.

8. Гавами тыңлауларда катнашучылар гавами тыңлаулар барышына тыкшынырга, аларны туктатырга һәм аларны үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел.

9. Ачык тыңлауларда катнашучылар тарафыннан уздыру тәртибе бозылган очракта, рәислек итүче аларны утырыш залыннан чыгаруны таләп итәргә хокуклы.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Шеланга авыл җирлеге башлыгы В.В.Майоров